**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 3 октябрь № 702

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 18 апрель, 192 нче; 2006 ел, 21 апрель, 199 нчы; 2007 ел, 7 ноябрь, 621 нче; 2008 ел, 28 март, 196 нчы; 2008 ел, 2 октябрь, 720 нче; 2010 ел, 28 октябрь, 864 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1042 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 17 март, 197 нче; 2011 ел, 13 сентябрь, 762 нче; 2012 ел, 16 март, 221 нче; 2012 ел, 24 март, 237 нче; 2012 ел, 6 август, 668 нче; 2012 ел, 26 декабрь, 1153 нче; 2013 ел, 31 гыйнвар, 54 нче; 2013 ел, 14 март, 161 нче; 2013 ел, 14 май, 323 нче; 2014 ел, 12 апрель, 238 нче; 2014 ел, 8 июль, 471 нче; 2014 ел, 8 август, 575 нче; 2015 ел, 10 август, 578 нче; 2015 ел, 24 декабрь, 969 нчы; 2016 ел, 22 гыйнвар, 32 нче; 2016 ел, 15 июнь, 405 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«министр урынбасарлары, Министрлыкның структур бүлекчәләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлегенең төп нәтиҗәлелек күрсәткечләре исемлеген раслый;

Министрлыкка беркетелгән функцияләр процессларын (ярдәмче процессларын) үтәү стандартларын боерыгы белән раслый;

эшчәнлек нәтиҗәлелегенең төп ирешелгән күрсәткечләренә бәйле рәвештә стимуллаштыручы түләүләр күләмен исәпләү тәртибен билгеләү хакындагы нигезләмәне раслый;

Министрлык өчен билгеләнгән төп эшчәнлек нәтиҗәлелеге күрсәткечләре һәм хезмәт законнары нигезендә ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләре белән контрактлар (хезмәт шартнамәләренә өстәмә килешүләр) төзи;»;

түбәндәге эчтәлекле 5.6 нчы пункт өстәргә:

«5.6. Министрлыкның структур бүлекчәләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү министр боерыгы белән расланган төп эшчәнлек нәтиҗәлелеге күрсәткечләре нигезендә гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\702.doc